Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

5 июнь 2020 ел № 720

2020 елның II кварталына Әлмәт муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 кв. метрының уртача базар бәясен раслау турында.

«2020-2025 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын, «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2020 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 13 мартындагы 122/пр номерлы боерыгы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы буенча 2020 елның II кварталына гомуми торак мәйданының 1 кв. метрының уртача базар бәясен 53 024 сум күләмендә расларга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов